ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап хакында

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Казан (Идел буе) федераль университетының Татарстан Республикасын фәнни-технологик үстерүгә һәм югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә, дәүләт хезмәткәрләрен, педагогларны һәм табибларны яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификацияләрен арттыруга, сәламәтлек саклау системасын һәм гомуми белем бирүне ныгытуга керткән өлешен, фәнни тикшеренүләрне һәм эшләнмәләрне арттыруда һәм гамәлгә ашыруда, икътисадка һәм социаль өлкәгә заманча технологияләр кертүдә әйдәп баручы булуын билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны хупларга.

2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы, шул исәптән Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүгә юнәлдерелгән проектлар, кысаларында үсеш программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә.

2.2. 2024 елда Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын үткәрү планы чараларында Казан (Идел буе) федераль университеты студентларының һәм фәнни-педагогик хезмәткәрләренең актив катнашуына булышырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең 220 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча төп чаралар планын гамәлгә ашыруда ярдәм итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәмmәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2337-VI ДС